ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 49 статьяда:
а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Балага исем ата-ана ризалыгы белән бирелә. Ата-ана балага исем сайлаганда аның исемендә цифрларны, хәрефле-цифрлы билгеләрне, саннарны, «дефис» билгесеннән тыш, символларны һәм хәреф булмаган тамгаларны яисә аларның теләсә нинди кушылмаларын йә сүгенү сүзләрен куллану, рангларны, вазыйфаларны, титулларны күрсәтү рөхсәт ителми.»;
б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Балага атасының исеме атасы исеме белән бирелә йә ата-ана ризалыгы белән атасының исеме милли традицияләр нигезендә баланың атасы исеменә «улы» (ир бала өчен) сүзе, «кызы» (кыз бала өчен) сүзе өстәлү юлы белән бирелергә мөмкин.»;
в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Ата-ананың фамилияләре төрле булганда, аларның ризалыгы белән балага атасының фамилиясе, анасының фамилиясе яисә атасының һәм анасының фамилияләре бер-берсенә теләсә нинди эзлеклелектә кушылу ярдәмендә төзелгән икеләтелгән фамилия бирелә, йә, милли традицияләрне исәпкә алып, баланың фамилиясе атасының исеменнән яисә баланың атасы ягыннан да, баланың анасы ягыннан да бабасының исеменнән алынырга мөмкин. Бер атадан һәм бер анадан туган ир балаларга һәм кыз балаларга икеләтелгән фамилия бирелгәндә, атаның һәм

ананың фамилияләре кушылу эзлеклелеген үзгәртү рөхсәт ителми. Баланың икеләтелгән фамилиясе иң күбе дефис аша кушып язылган ике сүздән генә торырга мөмкин.»;

г) 8 өлештә «халыкны социаль яклау оешмасы» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 57 статьяның 6 өлешендә «тәрбияләү учреждениеләреннән» сүзләрен «мәгариф оешмаларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3) 60 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «тәрбияләү учреждениесеннән» сүзләрен «мәгариф оешмасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 74 статьяның 2 өлешендә «тәрбияләү учреждениеләрендәге» сүзләрен «мәгариф оешмаларындагы» сүзләренә алмаштырырга;

5) 120 статьяның 3 өлешендә «тәрбияләү учреждениеләрендә» сүзләрен «мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 05 июль
№ 44-ТРЗ